**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 13 апрелендәге 1201 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 17 ноябрендәге 4000 номерлы**
**«“2023-2025 елларга «Имин шәһәр» аппарат-программа**
**комплексы сегментын төзү һәм үстерү” муниципаль программасын**
**раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 27 декабрендәге 5435 номерлы «Казан шәһәре Думасының 2024 елның 18 декабрендәге 3-35 номерлы “2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында”гы карарын гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карарындагы таләпләрне исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 17 ноябрендәге 4000 номерлы «“2023-2025 елларга «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексы сегментын төзү һәм үстерү” муниципаль программасын раслау турында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 24 ноябрендәге 3684 номерлы, 2024 елның 1 июлендәге 2771 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 1 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. программа паспортында «Елларга һәм чыганакларга бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| | |
|---|---|
| «Елларга һәм чыганакларга бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 1 137 451,07 мең сумны тәшкил итә, шуларның 1 129 442,20 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына, 8 008,87 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына. |

| Ел | Статья | Акча күләме, мең сум | |
|---|---|---|---|
| | | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты |
| 2023 | 0113 | 48 067,63 | 54,43 |
| | 0707 | 9 804,23 | |
| | 0709 | 199 184,59 | 1 480,12 |
| | 0804 | 37 439,80 | |
| | 1101 | 16 748,90 | |
| | | **311 245,15** | **1 534,55** |
| 2024 | 0113 | 81 661,26 | 1 509,76 |
| | 0707 | 17 129,53 | |
| | 0709 | 261 742,28 | 4 964,56 |
| | 0804 | 31 905,27 | |
| | 1101 | 16 587,12 | |
| | | **409 025,46** | **6 474,32** |
| 2025 | 0113 | 99 550,89 | |
| | 0707 | 13 023,96 | |
| | 0709 | 244 227,80 | |
| | 0804 | 35 247,60 | |
| | 1103 | 17 121,34 | |
| | | **409 171,59** | |
| **БАР-ЛЫГЫ** | | **1 129 442,20** | **8 008,87** |

Искәрмә. Финанслау күләмнәре фаразлау характерында бирелә. Аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»

1.2. III «Ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү» бүлегендәге таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

| «Ел | Акча күләме, мең сум | |
|---|---|---|
| | **Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты** | **Татарстан Республикасы бюджеты** |

| | | |
|---|---|---|
| 2023 | 311 245,15 | 1 534,55 |
| 2024 | 409 025,46 | 6 474,32 |
| 2025 | 409 171,59 | |
| **БАР-ЛЫГЫ** | **1 129 442,20** | **8 008,87»** |

1.3. «2023-2025 елларга “Имин шәһәр” аппарат-программа комплексы сегментын төзү һәм үстерү» муниципаль программасына кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә редакцияләргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 13 апрелендәге
1201 номерлы карарына
кушымта

**Программаның максатлары, бурычлары, төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чараларын финанслау**

| Төп чараларның атамалары | Башкаручы | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Финанслау (чыганагын күрсәтеп), мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 (база елы) | 2023 | 2024 | 2025 | 2023 | 2024 | 2025 |
| Максат: җәмәгать куркынычсызлыгының, хокук тәртибенең һәм яшәү тирәлеге иминлегенең гомуми дәрәҗәсен арттыру | | | | | | | | | | |
| Бурыч: муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында, Казан шәһәренең җәмәгать киңлекләрендә, паркларда һәм скверларда, җәмәгать фикерен белдерү урыннарында куркынычсызлык системаларын оештырганда, заманча мәгълүмат технологияләрен кертү | | | | | | | | | | |
| 1. Җәмәгать киңлекләрендә, паркларда һәм скверларда, җәмәгать фикерен белдерү урыннарында видеокүзәтү алып бару эшен үстерү | «Телекоммуникация технологияләре департаменты» МБУ | 2023-2025 | Объектларның гомуми саныннан видеокүзәтү системаларына хезмәт күрсәтелә һәм алар ремонтлана торган объектлар өлеше (%) | 65 | 98 | 98 | 98 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 16 281,4 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 23 983,95 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 28 256,0 |

| **Төп чараларның атамалары** | **Башкаручы** | **Төп чараларны башкару вакыты** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре** | **Индикатор күрсәткечләре** | | | | **Финанслау (чыганагын күрсәтеп), мең сум** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 (база елы) | 2023 | 2024 | 2025 | 2023 | 2024 | 2025 |
| 2. Муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында видеокүзәтү алып бару эшен үстерү | «Телекоммуникация технологияләре департаменты» МБУ | 2023-2025 | Видеокүзәтү системалары белән тәэмин ителгән муниципаль милектәге социаль өлкә объектлары өлеше (%) | 98 | 98 | 98 | 98 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 106 763,09 ТР бюджеты – 1 089,2 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 105 320,75 ТР бюджеты – 3 552,6 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 110 087,48 |
| 3. Муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында янгын куркынычсызлыгын арттыру | «Телекоммуникация технологияләре департаменты» МБУ | 2023-2025 | Социаль өлкә объектларындагы автоматлаштырылган янгын сигнализациясе системаларының һәм эвакуация турында хәбәр итү, эвакуация белән идарә итү системаларының гомуми санынннан ремонтланган һәм яңартылган системаларның өлеше (%) | 95 | 100 | 100 | 100 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 141 016,03 ТР бюджеты – 390, 92 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 200 939,68 ТР бюджеты – 1 411,96 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 178 022,72 |

| Төп чараларның атамалары | Башкаручы | Төп чаралар-ны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Финанслау (чыганагын күрсәтеп), мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 (база елы) | 2023 | 2024 | 2025 | 2023 | 2024 | 2025 |
| 4. Муниципаль милектәге социаль өлкә объектларында мәгълүмат чыганакларының һәм куркынычсызлык системаларының техник торышын мониторинглау, ведомствоара хезмәттәшлекне оештыру | «Телекоммуника-ция технологияләре департаменты» МБУ | 2023-2025 | Социаль өлкә объектларында куркынычсыз-лыкны тәэмин итү системаларының гомуми санынннан ремонтланган һәм яңартылган системаларның өлеше (%) | 80 | 100 | 100 | 100 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 1 327,00 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 1 131,88 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 880,77 |
| 5. «Телекоммуника-ция технологияләре департаменты» МБУ эшчәнлеген тәэмин итү өчен шартлар булдыру | «Телекоммуника-ция технологияләре департаменты» МБУ | 2023-2025 | Ихтыяҗларының гомуми дәрәҗәсеннән департаментның матди-техник яктан тәэмин ителеш дәрәҗәсе (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 45 382,85 ТР бюджеты – 54,43 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 77 033,0 ТР бюджеты – 1 509,76 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 90 962,32 |
| 5.1. Төп чараларны, шул исәптән җиһазлар сатып алу, хезмәткәрләрнең хезмәт хакы, элемтә | «Телекоммуника-ция технологияләре департаменты» МБУ | 2023-2025 | Штат санынннан департаментның кадрлар белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |

| **Төп чараларның атамалары** | **Башкаручы** | **Төп чараларны башкару вакыты** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре** | **Индикатор күрсәткечләре** | | | | **Финанслау (чыганагын күрсәтеп), мең сум** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 (база елы) | 2023 | 2024 | 2025 | 2023 | 2024 | 2025 |
| хезмәтләре, мәгълүмат тапшыру хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, җиһазларга техник хезмәт күрсәтү һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү | | | Департаментның финанс-хуҗалык эшчәнлеге планыннан аның эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү дәрәҗәсе (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| 6. Казан шәһәре Башкарма комитеты карамагындагы административ биналарда куркынычсызлык системаларын оештыру һәм аларга техник хезмәт күрсәтү | «Телекоммуникация технологияләре департаменты» МБУ | 2023-2025 | Казан шәһәре Башкарма комитеты карамагындагы административ биналарда куркынычсызлыкны тәэмин итүнең ремонтланган һәм модернизацияләнгән системалары өлеше (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 474,78 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 616,2 | Казан шәһәре МБ бюджеты – 962,30 |
| **Казан шәһәре бюджеты акчалары хисабына БАРЛЫГЫ** | | | | | | | | 311 245,15 | 409 025,46 | 409 171,59 |
| **Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына БАРЛЫГЫ** | | | | | | | | 1 534,55 | 6 474,32 | |
| **БАРЛЫГЫ** | | | | | | | | 312 779,70 | 415 499,78 | 409 171,59 |

Кабул ителгән кыскартулар:

Казан шәһәре МБ бюджеты – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты;

ТР бюджеты – Татарстан Республикасы бюджеты;

«Телекоммуникация технологияләре департаменты» МБУ – «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе.